# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ
# КАРАРЫ

**№1** **11.11.2019**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы
Чалпы авыл җирлеге составына керүче,
Камышлы авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2019 елның 11 ноябрендә түбәндәге сорау буенча узган, гражданнар җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде:

«Сез, 2020 елда, Чалпы авыл җирлеге Камышлы торак пункты территориясендә 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Камышлы авылында Молодежная урамнары буенча вак таш җәелгән юлларның чокырларын ямау (ташу, вак таш җәю, килешү буенча эш өчен түләү);
- Камышлы авылында урамнарны яктырту өчен яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу, энергияне саклый торган лампалар урнаштыру, эшләр өчен түләү;
- Камышлы авылы территориясендә көнкүреш калдыкларын һәм чүп-чарны вакытлыча җыю урыннарын чистарту;
- Камышлы авылы зиратлары өчен җиһазлар һәм инвентарь сатып алу;
- Камышлы авылында янгын сүндергечләр, янгын сүндерү ранецлары, янгынга каршы инвентарь сатып алу;
- Камышлы юлларын кардан чистарту;
- Камышлы авылы территориясен җәйге чорда чабу;
- Камышлы авылында коры агачлар, куакларны кисү;
- Камышлы авылында су белән тәэмин итү челтәрләрен ремонтлау (материал, җиһазлар сатып алу, өзеклекләрне бетерү, торбаларны алыштыру, килешү буенча эш өчен түләү);
- Камышлы авылында һәлак булган сугышчыларга куелган һәйкәлләрне ремонтлау (койма урнаштыру, буяу, агарту, килешү буенча эш өчен түләү) ;
- Камышлы авылында урам исемнәре язылган табличкалар әзерләү;
- Камышлы авылындагы гидротехник корылма янында «су коенырга ярамый» дигән табличкалар ясау, урнаштыру;
- Камышлы авылында «Яңа ел», «Җиңү көне», «Сабантуй», «Халыкара өлкәннәр көне») бәйрәм чараларын оештыру һәм үткәрү;

«ӘЙЕ» «ЮК».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Җыенда, сайлау хокукына ия булучы катнашучылар исемлегендә 63 кеше теркәлгән, җыенда тавыш бирүдә катнашучылар саны - 49 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
халык җыенында катнашучы 49 кеше «Әйе» позициясе өчен тавыш бирде; җыенда катнашучы 0 кеше «Юк» позициясе өчен тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар чыгарды:

1. Азнакай муниципаль районы Чалпы авыл җирлеге составына керүче Камышлы авылыдна узган халык җыенын узган, халык җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. Түбәндәге сорау буенча карарны кабул итәргә: «Сез, 2020 елда, Чалпы авыл җирлеге Камышлы торак пункты территориясендә 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Камышлы авылында Молодежная урамнары буенча вак таш җәелгән юлларның чокырларын ямау (ташу, вак таш җәю, килешү буенча эш өчен түләү);

- Камышлы авылында урамнарны яктырту өчен яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу, энергияне саклый торган лампалар урнаштыру, эшләр өчен түләү;

- Камышлы авылы зиратлары өчен җиһазлар , инвентарь, төзелеш материаллары сатып алу;

- Камышлы авылында янгын сүндергечләр, янгын сундерү ранецлары, янгынга каршы инвентарь сатып алу;

- Камышлы юлларын кардан чистарту;

- Камышлы авылында һәлак булган сугышчыларга куелган һәйкәлләрне ремонтлау (койма урнаштыру, буяу, агарту, килешү буенча эш өчен түләү) ;

- Камышлы авылында «Яңа ел», «Җиңү көне», «Сабантуй», «Халыкара өлкәннәр көне») бәйрәм чараларын оештыру һәм үткәрү.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru. һәм түбәндәге адрес буенча урнашкан мәгълүмат стендларында урнаштырырга: ТР, Азнакай муниципаль районы, Камышлы авылы мәдәният йорты, кибет.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Чалпы авыл җирлеге Башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Чалпы авыл җирлеге Башлыгы: А.М. Мөхәмәтшин